**Татарстан Республикасы**
**Лениногорск муниципаль районы**
**Иске Иштирәк авыл җирлеге**
**Бәкер авылында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2020 елның 21 ноябре № 2

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлегенең Бәкер авылында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Иске Иштирәк авыл җирлеге Бәкер авылы гражданнары җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, беренче һәм икенче төркем инвалидлар, көндезге уку формалары студентлары (укучылары) тыш, 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

- җирлекнең су үткәрү мөлкәтен ремонтлау объектларының расланган исемлеге нигезендә бирелгән вәкаләтләр нигезендә суүткәргеч мөлкәтен карап тоту;
- урамнарны яктыртуны оештыру;
- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә юлларны карап тоту;
-Бәкре авылында җирле әһәмияттәге юлларга вак таш җәю;
- җирлек территориясен төзекләндерү һәм яшелләндерү

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Иштирәк авылы, Мәктәп урамы, 5, Ялтау авылы, Тынычлык урамы, 27, Бәкер авылы, Нагорная, 38 адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Иске Иштирәк авыл җирлеге башлыгы А.А. Вәлиәхмәтов